ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унынчы утырышы көн тәртибе турында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасы Рәисен сайлауны билгеләү турында.
4. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.
5. «2024 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 75-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «2024 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 76-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 84-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 86-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 82-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 85-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 87-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 83-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 80-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 73-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 77-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 78-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 79-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 81-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

20. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 68-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

21. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 88-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

22. 2024 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап.

23. 2024 елда Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматы.

24. Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә матди һәм социаль гарантияләрне арттыру буенча кичектергесез чаралар күрү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.

25. «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 363942-8 номерлы федераль закон проекты турында.

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 866131-8 номерлы федераль закон проекты турында (җиңел таксида йөртүченең пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны пассажирларның гомерен, сәламәтлеген һәм мөлкәтен иминләштермичә гамәлгә ашырганы өчен җаваплылык билгеләү өлешендә).

27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.23 статьясындагы 3 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 868044-8 номерлы федераль закон проекты турында (балаларны йөртүгә карата билгеләнгән таләпләрне бозган өчен административ штрафлар күләмнәрен ике тапкырга арттыру максатларында).

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 875355-8 номерлы федераль закон проекты турында (монополиягә каршы федераль органга законнарда каралган үтенечнамәләр тапшырмаган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында).

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 17.15 һәм 23.68 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 897311-8 номерлы федераль закон проекты турында (мөлкәти булмаган характерга ия таләпләрне үтәмәгән өчен бюджетлар алучы бурычлыларның җаваплылыгын билгеләү хакында).

30. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәреш кертү турында» 847127-8 номерлы федераль закон проекты хакында (салым

түләүченең бердәм салым счетында уңай сальдо барлыкка китерә торган акчаларны кире кайтару турында).

31. «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 169 статьясына һәм «Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 888397-8 номерлы федераль закон проекты турында (махсус хәрби операциянең гамәлдәге катнашучысы булып торучы уллыкка алучының суд утырышында мәҗбүри булуы хакында таләпне төшереп калдыру өлешендә).

32. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 907585-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү процедурасын Россия Федерациясе субъектының лицензия комиссиясе институтын бетерү юлы белән камилләштерү өлешендә).

33. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 42 статьясындагы 3 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 884918-8 номерлы федераль закон проекты турында (балаларга психологик-педагогик ярдәм, медицина ярдәме һәм социаль ярдәм күрсәткәндә конфиденциальлек принцибын беркетү хакында).

34. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт музейлары өчен фонд саклагычлар биналарын төзү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Т.А. Голиковага Архангельск өлкә депутатлар Собраниесе мөрәҗәгате турында.

35. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеге турында».

36. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 282-VII ДС